**8. Песикәем**

Мәче баласы бар минем,
Йоклаганда мырылдый.
Шуна күрә бик яратам,
Ул бит миңа җыр җырлый.

Кушымта: Песи, песи пескәем,
Әйдә, утыр яныма!
Синең белән уйнасам,
Рәхәт була җаныма...

Мәче баласы бар минем,
Сәгать саен юына.
Бик сокланып карап торам
Анын уңганлыгына.

Кушымта: Песи, песи пескәем,
Әй, озындыр мыегың.
Нинди матур һәм йомшак,
Ак мамыктай койрыгың.

Мәче баласы бар минем
Күзгә карап утыра.
Китап ачсаң сырпалана,
'Өйрәт!'-диеп укырга!!

Кушымта: Песи, песи пескәем
Синең кебек уземдә,
Укый белмим әле мин,
"Әни "дигән сузне дә.